# ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районынын «Салагыш авыл җирлегенең» муниципаль берәмлеге Салагыщ торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**2022 нче ел, 07 март** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның «07» март 15 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

"2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Салагыш торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, ялгыз карт гражданнардан (80 яшькә җиткән), көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче затлардан һәм ирektән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум куләмендә узара салым акчалары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

-Салагыш авылы территориясендә су насослары, суүткәргеч челтәрләрне ремонтлау өчен сантехник материаллар сатып алу;

-Салагыш авылында урамнарны яктырту өчен лампалар, дроссельләр, фонарьлар, материаллар сатып алу һәм алыштыру;

-Салагыш урамнарын кардан чистарту (дизель ягулыгы һәм май сатып алу);

-Салагыш авылында Ленин урамы өчен вак таш сатып алу һәм аны җәю;

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 313 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны-160 кеше, бу 51,1% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенынnda 158 катнашучы тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 2 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салауш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Салагыш торак пунктында

гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – дөрес дип таныргa

2. 2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салауш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Салагыш торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, ялгыз карт гражданнардан (80 яшькә җиткән), көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче затлардан һәм иректән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә узара салым чаралары җыюны кертүгә.

3.Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

-Салагыш авылы территориясендә су насослары, сууткәргеч челтәрләрне ремонтлау өчен сантехник материаллар сатып алу,;

-Салагыш авылында урамнарны яктырту өчен лампалар, дроссельләр, фонарьлар, материаллар сатып алу һәм алыштыру;

-Салагыш урамнарын кардан чистарту (дизель ягулыгы һәм май сатып алу);

-Салагыш авылында Ленин урамы өчен вак таш сатып алу һәм аны җәю.

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.agryz.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе М.М. Мөхәммәдиев